РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 7 декабре № 55

Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 60 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 60 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Муниципаль торак контроле Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты яки җирле үзидарәнең башка органы тарафыннан Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында төзелгән килешүгә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла (алга таба – контроль органы).»;

1.6 пунктны түбәндәге эчтәлектәге сүзләр белән тулыландырырга:

«, яки Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында төзелгән килешүгә ярашлы рәвештә җирле үзидарәнең башка җаваплы кешесе.»;

Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымта) бәян итәргә.

1. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.Х. Муллин

Түбән Кама шәһәр
Советының 2023 елның
7 декабрендәге
55 номерлы карарына кушымта

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль чараларын үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы күрсәткечләре

1. Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясының 1 өлеше белән билгеләнгән Контроль орган адресына гражданнардан яки күпфатирлы йортта биналар хуҗалары булган оешмалардан, күпфатирлы йортта биналардан файдаланучылар булган гражданнардан кергән алдагы календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда, вакыт берәмлегендә (ай, алты ай, унике ай) мөрәҗәгатьләр санының өч тапкыр һәм аннан да күбрәк артуы, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында мәгълүмат.

2. Өч ай эчендә күпфатирлы йортта хуҗалары булган гражданнан яки оешмадан алынган мәгълүматларның, күпфатирлы йортта кулланучы булган гражданнан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында контрольдә тотылган зат тарафыннан урнаштырылган массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларның туры килмәвенең биш фактыннан артыгын ачыклау.

3. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

4. Россия Федерациясе Торак Кодексының 165 статьясының 5 өлеше нигезендә билгеләнгән тәртипкә, формаларга, срокларга һәм вакытлыча ярашлы рәвештә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматның өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында актуальләшмәве.

5. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә торган зат күпфатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырылганда.

6. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләре өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.

Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары

М.В. Камелина